ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**
«25» март 2026 ел **№ 1**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бурнак авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларны кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибенә үзгәрешләр керту хакында

Бурнак авыл җирлеге башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 нчы маддәсенең 4 нче пунктында карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Бурнак авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларны кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә (эш бирүче) хәбәр итү тәртибенә 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1.«11.Муниципаль хезмәткәргә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яллаучы (эш бирүче), прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына аны коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында, башка дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциячел хокук бозуларны кылу фактлары, белешмәләрне тапшырмау, күрәләтә тулы булмаган белешмәләр тапшыру фактлары турында хәбәр иткән муниципаль хезмәткәр, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, йә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Бурнак авыл җирлеге башлыгы
вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы И.И.Габдуллин